| | | |
|---|---|---|
| **СОВЕТ ПОДГОРНО-БАЙЛАРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МЕНЗЕЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТАУАСТЫ БАЙЛАР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ** |

# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы
Тауасты Балар авыл җирлегенең Тауасты Балар торак пунктында
2025 елда гражданнарның үзара салым кертү турында

**15 ноябрь 2024 ел** **№ 3**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 елгы №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 елгы №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә,Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Тауасты Байлар авыл җирлегенең Тауасты Байлар торак пунктында гражданнар җыены

## КАРАР ЧЫГАРА:

1. «Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Тауасты Байлар авыл җирлеге Тауасты Байлар торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2025 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә,1 һәм 2 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы һәм сугышчан хәрәкәтләр ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында һәм сугышчан хәрәкәтләрдә катнашучыларның тол хатыннарыннан,көндезге формада укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына хезмәткә чакырылган гражданнардан, мобилизацияләнгәннәрдән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Тауасты Байлар торак пунктындагы 1 нче Тыкрык буенча юлга вак таш сатып алу һәм салу (эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен шартнамә буенча түләү);
- Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Тауасты Байлар торак пунктындагы 2 нче тыкрык буенча юлга вак таш сатып алу һәм салу (эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен шартнамә буенча түләү);
- Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Тауасты Байлар торак пунктында

кышкы чорда юлларны грейдерлау (эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен шартнамә буенча түләү).
- Су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (Тауасты Байлар торак пунктындагы су җыю башнясы скважинасы өчен насос сатып алу (эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү).

3.Әлеге карарны Тауасты Байлар авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Минзәлә муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (http:// menzelinsk.tatarstan.ru) кабул ителгән көннән алып 10 көн эчендә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Минзәлә муниципаль районы,
Тауасты Байлар авыл җирлеге башлыгы З.С.Гәрәева